# ГАРМУН

*Г.СӘФУЛЛИН көе*
*И.ХӨСНЕТДИНОВ шигыре*

Авыл буйлап гармун уйнап
Җырлыйсы иде тагы.
Искә төшә, сагындыра
Туган авылым ягы.

*КУШЫМТА:*
Сандугачларны уздыра
Кечкe тальян моңнары.
Сыздырып уйнап җибәрә —
Их, моңлы гармуннары.

Гармун моңнары тарала
Авыл урамнарына.
Кайтам әле авылыма —
Дуслар, туганнарыма.

Авылымда таллыгымда
Була кичке уеннар.
Уйна әле гармуныңны –
Сиңа дигән җырым бар.